ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 22 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 пунктының беренче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 16 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2025, № 33 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 75 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«8. Әлеге статьяның 6 һәм 7 пунктларында күрсәтелгән социаль ярдәм чараларына өстәмә рәвештә гаилә составында, уллыкка алынган балаларны да кертеп, өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга, өлкән балага 18 яшь яисә 23 яшь тулганчы, ул белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге уку рәвешендә белем алган очракта, яисә балачактан инвалид булган өлкән балага 23 яшь тулганчы, социаль ярдәмнең түбәндәге чаралары күрсәтелә:».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе
Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 25 июль
№ 46-ТРЗ